ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**24 декабрь 2021 ел** **№ 27**

**«Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы « Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, 17.11.2021 №1, 18.11.2021 №2 җыеннарда кабул ителгән «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы « Яңасала авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 28 октябрендәге 32 номерлы Яңасала авыл җирлеге Советы карары нигезендә Яңасала авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. « Яңасала авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Арча районы, Яңасала авылы, Үзәк урам, 18 йорт; Арча районы, Каенсар авылы, Урта урам, 25 йорт.

3. « Яңасала авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» Яңасала авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге 34 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңасала авыл
җирлеге башлыгы А.И. Сафин

Яңасала авыл җирлеге
Башкарма комитетының
24.12.2021 ел, №27 карарына
1 нче кушымта

**« Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип «Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчасы 2022 елның 18 февраленә кадәр «Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдергән мөнәсәбәтләре нинди булуга карамастан, 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан түләнә.

3. Аерым категория гражданнар:

а) көндезге уку формасы буенча укучы студентлар,

б) 1 төркем инвалидлар,

в) 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен

түләү күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

4. Нигезле сәбәпләр:

а) гаилә әгъзасының үлеме (ата-ана, хатыны/ире, балалары),

б) янгын яки башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсендә зыян күрү булганда

гражданнарга гариза нигезендә өч айдан артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында гражданнарга хәбәр итү хәбәрнамә бланкын Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру, шулай ук кул куйдырып шәхсән бирү яисә почта аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерү өчен түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан җыелган акчалар «Яңасала авыл җирлеге » муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчермәләрен (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла, «Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты кассасы яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша сылтама https://uslugi.tatarstan.ru/ буенча башкарыла.

8. Түләүне дәлилли торган документ булып касса керем ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Яңасала авыл җирлеге
Башкарма комитетының
24.12.2021 ел, №27 карарына
2 нче кушымта

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______________
«Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләү турында

Түләүченең ф. и. а.и.________________________________________________________
Адресы:_______________________________________________________________
_____________________________________________________________нигезендә
Сезгә __________ кадәр ________ сум күләмендә
___________________________________чаралар гамәлгә ашыру өчен
түбәндәге реквизитлар буенча:
БИК банк __________________________
Сч. № ______________________________________
Счетны алучы. № ______________________________
ИНН __________________________________________
КПП __________________________________________
КБК _________________ОКАТО__________________
Түләү билгеләнеше
____________________________________________________________________бер
тапкыр түләү түләргә кирәк.

Җитәкче _________________ ________________________________________

М. у. (имза) ( имзаны аңлату)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

«Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына __ сум күләмендә бер мәртәбә түләнә торган үзара салым түләү буенча хәбәр (хәбәрнамә) № ___
Түләүченең ф. и. а.и.__________________________________________
Адресы: _______________________________________________
Алдым «___» _______________ 20__ ел ____________________________________
(имза/түләүченең ф.и.а.и.)

*Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән бирелгән очракта, өзмә корешок тутырыла һәм ул Яңасала авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*